*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2018-2019 учебный год**

**10 класс**

**I. Сүзтезмәләрне фразеологик гыйбарәләр белән алыштырып языгыз.** / Напишите словосочетания, заменив фразеологическими оборотами (10 баллов).

1) Курку белмәс кеше – ____________________________________________
2) Ялкау кеше – ____________________________________________
3) Нык куллы кеше - ____________________________________________
4) Тынгысыз кеше - ____________________________________________
5) Гадел фикер йөртүче – ____________________________________________
6) Ихлас күңелле кеше – ____________________________________________
7) Бик зирәк кеше – ____________________________________________
8) Белемсез, надан кеше – ____________________________________________
9) Булдыксыз кеше – ____________________________________________
10) Яссы табанлы кеше – ____________________________________________

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен тутырып языгыз. /** Напишите полностью имя и фамилию авторов этих стихотворений. (10 баллов).

1) Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем,
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, туган телем,
Син өйрәттең миңа һәммәсен.

**Җавап**: ____________________________________________

2) Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнеңдә –
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
Матур итеп туган телеңдә!

**Җавап:**____________________________________________

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне тиешле формага куеп бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз /** Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов).

ТӨКЕРЕК, ТЕЗ, АВЫЗ, МЫЕК, ОЯ

Күке ____________________________________________
Карлыгач ____________________________________________
Карга ____________________________________________

Каз ______________________________

Чыпчык ______________________________

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз.** / Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. (20 баллов)

*Малын җуйган җиде ел елар, иленнән аерылган исә – гомере буе.*

Малын - ______________________________

______________________________

Җуйган - ______________________________

______________________________

Җиде - ______________________________

______________________________

Ел - ______________________________

______________________________

Елар - ______________________________

______________________________

Иленнән - ______________________________

______________________________

Аерылган - ______________________________

______________________________

Исә - ______________________________

______________________________

Гомере - ______________________________

______________________________

Буе - ______________________________

______________________________

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решити кроссворды (20 баллов)

**А) Бирелгән сүзләрнең синонимнарын языгыз./** Напишите синонимы данных слов.

**1. Ят -**
**2. Ышаныч -**
**3. Эпидемия -**
**4. Яңабаштан –**
**5. Хокук белгече -**
**6. Эш -**
**7. Поэзия -**
**8. Республика -**
**9. Дәлил -**
**10. Аксөяк -**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | т | | | | | | | |
| | | | т | | | | | | |
| | | | т | | | | | | |
| | | | | т | | | | | |
| | | | | т | | | | | |
| | | | | | т | | | | |
| | | | | | | | т | | |
| | | | | | | | т | | |
| | | | | | | | | т | |
| | | | | | | | | | т |

**Б) Парлы сүзнең беренче кисәген языгыз. /** Напишите первый компонент парного слова.

**1. ...-тирә**
**2. ...-төртелә**
**3. ...-фигыль**
**4. ...-тын**
**5. ...-шәфкать**
**6. ...-бәрелеп**
**7. ...-постык**
**8. ...-саулык**
**9. ...-талаш**
**10. ...-өнсез**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| я | | | | | | | |
| э | | | | | | | |
| х | | | | | | | |
| т | | | | | | | |
| р | | | | | | | |
| о | | | | | | | |
| к | | | | | | | |
| и | | | | | | | |
| к | | | | | | | |
| т | | | | | | | |

**VI. Татар теле этимологиясе турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз. /** Напишите об этимологии татарского языка (10 баллов).

*Исправления не допускаются*

**VII. “Китапларның тормышыбыздагы әһәмияте” дигән темага татар китаплары турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее 80 слов) о книгах на татарском языке на тему «Роль книги в нашей жизни». Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов).

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур (ответы)**
**2018-2019 учебный год**

**10 класс**

**I. Түбәндәге сүзтезмәләрне фразеологик гыйбарәләр белән алыштырып языгыз. /** Напишите словосочетания фразеологическими оборотами (*10 баллов. 10 словосочетаний и за каждый правильно приведенный фразеологизм по 1 баллу*).

1. Курку белмәс кеше – **арыслан йөрәкле, арыслан йөрәк**
2. Ялкау кеше – **авыр аяклы, авыр аяк, авыр санлы, авыр сөякле**
3. Нык куллы кеше – **авыр куллы**
4. Тынгысыз кеше – **агач корты**
5. Гадел фикер йөртүче – **аек фикерле, аек фикер, аек фикер иясе**
6. Ихлас күңелле кеше – **ак күңел, ак күңелле**
7. Бик зирәк кеше – **акылга беткән, акыл иясе**
8. Белемсез, надан кеше – **акылга сай, акылга бертөрле, ак ылга зәгыйфь, акылга таман, акылга туймый калган, акылга тулы түгел, акылга чамалы, акылга чак, акылдан буш (коры) калган**
9. Булдыксыз кеше – **аяклы каза**
10. Яссы табанлы кеше – **аю табан**

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен тутырып языгыз. /** Напишите полностью имя и фамилию авторов этих стихотворений. (10 баллов. 2 автора. За каждый правильно приведенный ответ по 5 б).

1) Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем,
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, туган телем,
Син өйрәттең миңа һәммәсен.
**Җавап**: **Хәсән Туфан**

2) Киләчәкнең башы – бүгенгедә.
Нинди шатлык картлык көнендә –
Оныкларың сиңа рәхмәт әйтсә
Матур итеп туган телеңдә!
**Җавап: Равил Фәйзуллин**

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне тиешле формага куеп бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз /** Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов. 5 примеров. За каждый ответ: 1 *балл - за краткий верный ответ + 1 балл – за верное толкование.*).

**Күке төкереге – аз табыш**
**Карлыгач мыек – карлыгач койрыгы кебек аеры, очры мыек**
**Карга авыз – ачык авыз, пешмәгән**

**Каз оясы – тузган өй, мамыгы-йоны тузган зур бүрек**
**Чыпчык тезеннән – сай, тирән булмаган**

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз. /** Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. *(20 баллов. За каждый полный верный ответ по 2 балла).*

*Малын җуйган җиде ел елар, иленнән аерылган исә – гомере буе.*

Малын -исем, тамыр сүз, берлек санда, өченче зат берлектәге тартым белән төрләнгән, төшем килешендә.

Җуйган - тамыр сүз, сыйфат фигыль, үткән заманда, затланышсыз, исемләшкән.

Җиде - тамыр сан, микъдар саны, ел санын ачыклап килгән.

Ел - тамыр сүз, исем, баш килештә, берлектә, тартым белән төрләнмәгән.

Елар – тамыр сүз, хикәя фигыль, затланышлы, өченче зат, берлек санда, билгесез киләчәк заманда.

Иленнән – тамыр сүз, исем, чыгыш килешендә, берлектә, өченче зат берлектәге тартым белән төрләнгән.

Аерылган - тамыр сүз, сыйфат фигыль, үткән заманда, затланышсыз, төшем юнәлешендә, исемләшкән.

Исә - кисәкчә

Гомере - исем, тамыр сүз, берлек санда, өченче зат берлектәге тартым белән төрләнгән, баш килештә.

Буе - бәйлек, баш килешне сораучы бәйлек, гомере сүзенә ияреп килгән.

**V. Кроссвордларны чишегез. /**Решити кроссворды (20 баллов. За каждое верно угадонное и написанное слово по 1 баллу)

**А) Бирелгән сүзләрнең синонимнарын языгыз./** Напишите синонимы данных слов.

**Җаваплар/Ответы**

1. **Ят - чит**
2. **Ышаныч - өмет**
3. **Эпидемия - үләт**
4. **Яңабаштан - кабат**
5. **Хокук белгече - юрист**
6. **Эш - хезмәт**
7. **Поэзия - шигърият**
8. **Дәлил - аргумент**
9. **Республика - җөмһүрият**
10. **Аксөяк - аристократ**

**Б) Парлы сүзнең беренче кисәген языгыз. /** Напишите первый компонент парного слова.

**Җаваплар/ Ответы:**

1. **якын-тирә**
2. **этелә-төртелә**
3. **холык-фигыль**
4. **тавыш-тын**

5. **рәхим-шәфкать**
6. **орылып-бәрелеп**
7. **калдык-постык**
8. **Исәнлек-саулык**
9. **Кычкырыш-талаш**
10. **Тавышсыз-өнсез**

**VI. Татар теле этимологиясе турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите об этимологии татарского языка (10 баллов. *2 балла - за краткий верный ответ, 8 баллов – за верное обоснование с примерами*).

**Җавап**: Этимология - сүзнең килеп чыгышын һәм мәгънә үсешен өйрәнә торган фән.
Халык этимологиясе - таныш булмаган алынма сүзнең мәгънәсен җиңел аңлашыла торган сүзләр җирлегендә аңлатырга тырышу. Х. э., кагыйдә буларак, җанлы сөйләмдә очрый, фәннилек белән бернинди уртаклыгы юк: *трамвай – утырамбай, тротуар – плитуар.ак* - *агы китап* - *китабы кара* - *карабрак һ.б.*
Этимология сүзнең мотивлаштыру мөмкинлеген, сәбәпләрен өйрәнә, мәгънә үсешендә барлыкка килгән үзенчәлекләрне ачыклый. Этимологиянең 3 принцибы билгеле: 1) фонетик принцип – телдәге тарихи аваз тәңгәллекләре нигезендә сүзнең беренчел вариантын торгызуны максат итеп куя, 2) семантик принцип – сүз мәгънәсенең тарих дәвамында үсеш-үзгәрешен өйрәнеп, сүзләр арасында мәгънә бәйләнешен торгызуны максат итә, 3) сүз ясалышы принцибы – сүзнең беренчел төзелешен торгызуны максат итеп куя.
Этимон (гр. etymon – чын) – сүзнең югалган, әмма махсус тикшеренүләр ярдәмендә торгызыла торган мәгънәсе һәм формасы: чая, шаян, шаяру сүзләренең этимоны – йай/җай (ж>ч-ц, ч>ш). Беренчел мәгънә югалу сүзнең тамырдаш берәмлекләре белән һәм фонетик яктан, һәм семантик яктан бәйләнеше өзелү нәтиҗәсендә барлыкка килә.

**VII. "Китапларның тормышыбыздагы әһәмияте" дигән темага татар китаплары турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / Напишите сочинение (не менее 80 слов) о книгах на татарском языке на тему «Роль книги в нашей жизни». Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов)___

| № | **Сочинениене бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |